| АЛЕКСЕЕВСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛЕКСЕЕВСК РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.02.2019 п.г.т. Алексеевское №231

**Алексеевск муниципаль районында гражданнарга шәхси торак төзү һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлекләре бирү нормалары турында**

Җиргә хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм сәясәтне тәэмин итү һәм тиешле законнарга туры китерү, шул исәптән Россия Федерациясенең 29 декабрь, 2004 ел, 190-ФЗ санлы Шәһәр төзү кодексының 30 нче маддәсе, 6 нчы өлеше, 136-ФЗ санлы 25 октябрь, 2001 ел, Россия Федерациясе җир кодексының 11.9 маддәсе 1 нче пункты нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә гражданнарга милек итеп һәм арендага җир кишәрлекләре бирүнең чик (максималь һәм минималь) нормаларын билгеләргә:

1.1. Алексеевск ш.т.б.да шәхси торак төзелеше өчен:

- җир кишәрлегенең максималь күләме – 1000 кв.м;
- җир кишәрлегенең минималь күләме – 400 кв.м.

1.2. шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен:

- җир кишәрлегенең максималь күләме – 2000 кв.м, яр буендагы торак пунктлар: Лебяжье, Саконы, Речное, Городок авыллары, Ивановский бистәсе, Балахчино, Березовая Грива, Лебедино авылларыннан кала, аларда бирелә торган җир кишәрлеге максималь күләме – 1000 кв.м;
- җир кишәрлегенең минималь күләме – 400 кв.м.

2. Әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән нормалар социаль ипотека системасында торак төзү өчен җир кишәрлекләре биргәндә кулланыла.

3. Әлеге карарның көче бирү нормасы федераль законда яки Татарстан Республикасы законында билгеләнгән җир кишәрлекләре бирү очракларына таралмый.

4. Әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән нормалар шәһәр төзелеше эшчәнлеге законнары нигезендә җир кишәрлекләренең чик (максималь һәм минималь) күләмнәрен билгеләгән очракта кулланылмый.

5. “Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм шәхси торак төзү өчен гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең чик (максималь һәм минималь) күләмнәре турында”гы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советының 22 апрель, 2011 ел, 71 нче карарын көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча Алексеевск муниципаль районы Советының даими депутатлар комиссиясенә йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**